ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТАТАРСКО-ТОЛКИШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

422961, Республика Татарстан,
Чистопольский район,
село Татарский Толкиш, ул.Советская,
дом 4

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР ТАЛКЫШЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422961, Татарстан Республикасы,
Чистай районы, Татар Талкышы авылы,
Совет урамы, 4 нче йорт.

тел. 884342 3-32-23, e-mail:Ttolk.Ctp@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22 июнь 2023 ел № 18

Нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2022 елның 14 июлендәге 339-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 2021 елның 17 мартындагы 5 номерлы карары белән расланган нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 1.5 пунктында һәм 2.3 пунктында 1-12 пунктчаларын түбәндәге эчтәлекле 1-13 пунктчаларына алмаштырырга:

«1) күчемсез мөлкәт белән эш итүгә ышанычнамәләрдән тыш, ышанычнамә таныклыгы;

2) мирас мөлкәтен мирас мөлкәте исемлеген төзү юлы белән саклау буенча чара күрү;

3) документлар күчермәләренең һәм алардан өзекләрнең дөреслеген раслау;

4) документлардагы имзаның чынлыгын раслау;

5) Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда затлар турында мәгълүмат таныклыгы;

6) гражданның исән булу фактын раслау;

7) тиешле җирлек яки муниципаль район территориясендә яшәүче күз күрүе буенча инвалидның үз куллары белән имзаланган имзасы факсимиль рәвештәге имзасы белән бер үк булуын раслау;

8) гражданның билгеле бер урында булу факты таныклыгы;

9) фоторәсемдә күрсәтелгән зат белән гражданның бердәйлеге таныклыгы;

10) документларны тапшыру вакыты таныклыгы;

11) электрон документның кәгазь чыганактагы документка тиңлеген раслау таныклыгы;

12) кәгазь чыганактагы документның электрон документка тиңлеген раслау таныклыгы;

13) нотариаль таныкланган килешүләрнең эчтәлеген чагылдыра торган документларның дубликатларын бирү.»;

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында яисә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татар Талкышы
авыл җирлеге башлыгы М.М. Вәлиев